# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында

1 статья. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасының 1998 елның 22 декабрендәге Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №12; 1999 ел, №6, №9) түбәндәге редакциядә сигезенче өлеш өстәргә:

«Иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзаларын үтәүче учреждениеләрне, шулай ук Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Җәза үтәтү идарәсе предприятиеләрен һәм оешмаларын 1999 елның 1 гыйнвареннан Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә өстәлгән бәяләргә салым түләүдән һәм Татарстан Республикасында Юллар фондына, Татарстан Республикасының Экология фондына салымнардан һәм башка түләүләрдән азат итәргә».

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2429